МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.10.2016 г. Казань № 897 од

Татарстан Республикасы театрларының
профессональ иҗат хезмәткәрләрен аттестацияләүнең
типик нигезләмәсен раслау турында

«Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 2016 елның 11 июнендәге 43-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына нигезләнеп

**БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт театрларының профессиональ иҗат хезмәткәрләрен аттестацияләүнең теркәлгән типик нигезләмәсен (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт театрларына 2016 елның 1 декабренә кадәр вакыт эчендә профессиональ иҗат хезмәткәрләрен аттестацияләү турында нигезләмә әзерләргә һәм расларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **А.М.Сибагатуллин**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2016 елның «18» 10
89709 номерлы
боерыгы белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕАТРЛАРЫНЫҢ ПРОФЕССИОНАЛЬ ИҖАТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕН АТТЕСТАЦИЯЛӘҮ ТУРЫНДА ТИПИК НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы дәүләт театрларының (алга таба – Театрлар) профессиональ иҗат хезмәткәрләрен, ягъни театрның сәнгати персоналы һәм театрның иҗади составын (труппа) (алга таба – хезмәткәрләр) аттестацияләү Театр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны, театраль постановкаларны сыйфатлы әзерләүне тәэмин итүне, Татарстан Республикасы дәүләт театрларында кадрлар рациональ сайлап алу максатларында үткәрелә.

1.2. Аттестациянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы дәүләт театрларының югары квалификацияле кадрлар составын формалаштыру;

хезмәткәрләрнең биләгән вазыйфаларына туры килүен билгеләү;

хезмәткәрләрнең профессиональ сыйфатларын, потенциаль мөмкинлекләре перспективасын ачыклау;

хезмәткәрләрнең профессиональлеген үстерүгә стимул тудыру;

хезмәткәрләрнең квалификациясен үстерүгә, профессиональ әзерлеккә яки кабат әзерләүгә ихтыяҗын билгеләү;

карьерасын үстерү мөмкинлеген тәэмин итү.

1.3. Аттестацияне Татарстан Республикасы дәүләт театрларында эшләүче хезмәткәрләр үтәргә тиеш.

Аттестацияне түбәндәгеләр үтми:

авырлы хатын-кызлар;

бала карау буенча ялда булган һәм өч яшькә кадәрге баласы булган затлар (андый затларга аттестация уздыру өчен ялдан чыкканнан соң бер елдан азрак вакыт үтәргә тиеш түгел);

биләгән вазыйфаларында бер елдан азрак вакыт эшләүче хезмәткәрләргә;

берьюлы ике урында эшләүчеләр.

2. Аттестация уздыру сроклары һәм аттестация комиссиясе составы

2.1. Аттестация биш елга бер мәртәбә үткәрелә – чираттагы (планлы) аттестация.

2.2. Алдагы аттестация үткәрелгәннән соң биш ел үткәнче үк хезмәткәргә чираттан тыш (планнан тыш) аттестация үткәрелергә мөмкин. Чираттан тыш аттестация түбәндәге очракларда үткәрелә:

Театрның бер яисә берничә хезмәткәренең эше канәгатьләнерлек булмавының объектив сәбәпләрен ачыклау ихтыяҗы туганда;

квалификациясе һәм профессиональ сыйфатлары югарырак вазыйфаны биләргә мөмкинлек биргән хезмәткәрне объектив нигездә сайлап алу ихтыяҗы булганда;

югарырак вазыйфага алынырга теләк белдергән яисә күтәрелеп китү өчен үз кандидатурасын тәкъдим иткән хезмәткәрнең үтенече булганда.

2.3. Аттестацияләнергә тиешле затлар исемлеге, аттестация үткәрелү графигы, аттестация үткәрүнең нигезләре (аттестация планнан тыш булса) Театр җитәкчесе боерыгы белән раслана һәм һәр аттестацияләнәсе хезмәткәргә бер айдан да ким булмаган вакыт аралыгында хәбәр ителә.

Аттестация сроклары Театрның штат саныннан чыгып, Театр җитәкчесе боерыгы белән билгеләнә. Аттестация үткәрүнең максималь срогы – 6 ай.

2.4. Аттестация үткәрү графигында хезмәткәрнең фамилиясе, вазыйфасы, аттестация үткәрелү һәм аттестация комиссиясенә тиешле документларны тапшыру датасы, шулай ук аттестация үткәрелү өчен җаваплы хезмәткәрләрнең вазыйфалары һәм фамилияләре күрсәтелә.

2.5. Театрларда оештырылган аттестация комиссиясе составына рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары, шул исәптән тиешле профсоюз оешмалары һәм иҗат берлекләре вәкилләре кертелә.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 82 статьясына нигезләнеп, аттестация үткәргәндә, ул Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына туры китереп хезмәткәрне эштән азат итәргә нигез булып торырга мөмкин булганлыктан, аттестация комиссиясе составына мәҗбүри рәвештә тиешле профсоюз оешмасының сайлау органы вәкиле кертелә.

Аттестация комиссиясе рәисе вакытлыча катнаша алмаса (авыру, ял, командировка һәм башка игътибарга лаеклы сәбәпләр), аттестация комиссиясе рәисе вәкаләтләрен аттестация комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Аттестация комиссиясе утырышы комиссия рәисе тарафыннан чакырыла.

2.6. Театрның аттестация комиссияләренең персональ составы Театр җитәкчесе боерыгы белән раслана.

## 3. Аттестация үткәрү тәртибе

3.1. Аттестация үткәрелер алдыннан Театр администрациясе тарафыннан, тиешле профсоюз берлеге катнашында, аңлату һәм әзерлек эшләре башкарыла.

3.2. Аттестация аттестацияләнә торган хезмәткәрнең эшчәнлеген объектив бәяләп, хәбәрдәрлек шартларында һәм хезмәт законнарына таянып үткәрелә.

Хезмәткәрне аттестацияләгәндә аттестация комиссиясе аерым спектакльләрне, театральләштерелгән концерт программаларын һәм репетицияләрне карап, шулай ук хезмәткәр белән әңгәмәләшеп, хезмәткәрнең иҗади мөмкинлекләре һәм квалификациясе белән таныша.

3.3. Аттестация үткәрелергә тиешле һәр хезмәткәргә җитәкчесе тарафыннан хезмәт бәяләмәсе (отзыв) әзерләнә, ул аттестация үткәрелергә ике атна кала аттестация комиссиясенә тапшырыла. Аттестацияләнә торган хезмәткәр бәяләмә (отзыв) белән танышырга тиеш.

Бәяләмәдә (отзыв) хезмәткәрнең профессиональ, эшлекле һәм шәхси сыйфатлары төрле яклап, тулы һәм объектив күрсәтелергә; хезмәткәрнең профессиональ әзерлеге вазыйфаның квалификацион таләпләренә туры килүенә; эшенә мөнәсәбәтенә һәм вазыйфаи бурычларын үтәвенә; үткән аттестация арасындагы чорда эшчәнлек нәтиҗәләре күрсәткечләренә бәя бирелергә тиеш.

Алдагы аттестацияләрдә аттестация комиссиясенә үткән аттестациянең аттестация бите дә тапшырыла.

3.4. Аттестация үтәсе хезмәткәр аттестациягә бер айдан ким булмаган вакыт калганда әлеге Нигезләмә белән танышырга тиеш.

3.5. Аттестация аттестацияләнүче хезмәткәр катнашында үткәрелә.

3.6. Аттестация үтәсе хезмәткәр, аттестация үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр ителеп тә, җитди сәбәпләрсез аттестация комиссиясе утырышына килмәгән очракта, комиссия аттестацияне аннан башка гына үткәрә.

3.7. Аттестация комиссиясе бирелгән материалларны карый, аттестацияләнүчене һәм ул эшләгән бүлекчәнең җитәкчесен тыңлый.

3.8. Аттестация комиссиясе утырышы барышы секретарь яисә аттестация комиссиясе әгъзаларының берсе тарафыннан теркәлеп барыла.

3.9. Хезмәткәрнең профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү турында карар, шулай ук аттестация комиссиясенең рекомендацияләре аттестацияләнүчедән башка ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы аттестация комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышыннан чыгып кабул ителә.

Аттестация комиссиясе эшендә аның әгъзаларының 2/3 дән дә ким булмаган өлеше катнашса, тавыш бирү дөрес дип санала. Тавышлар тигез

булса, аттестацияләнгән хезмәткәр билгеләнгән вазыйфасына туры килә дип таныла.

Тавыш бирү аттестацияләнүченең үзеннән башка уздырыла.

3.10. Аттестация комиссиясе әгъзасы булган хезмәткәр үзе аттестация үткәндә тавыш бирүдә катнаша алмый.

3.11. Аттестация нәтиҗәләре аттестация битенә (теркәлгән) кертелә. Аттестация битенә аттестация комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашкан һәм тавыш биргән комиссия әгъзалары кул куя.

3.12. Аттестация комиссиясе карары, тавыш бирүгә йомгак ясалганнан соң, аттестацияләнүчегә җиткерелә.

Аттестацияләнгән хезмәткәр аттестация бите белән танышып имзасын куя.

Аттестацияләнгән хезмәткәр аттестация битенә имза салудан баш тартса, аттестацияләнгән хезмәткәрнең алда күрсәтелгән документка кул куюдан баш тартуы турында аттестация комиссиясе рәисе имзасы белән акт төзелә.

3.13. Аттестация үткән хезмәткәрнең аттестация бите һәм аңа бәяләмә хезмәткәрнең шәхси эше эчендә саклана.

3.14. Аттестация нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

биләгән вазыйфасына туры килә;

хезмәт эшчәнлеге буенча аттестация комиссиясе рекомендацияләрен үтәсә, биләгән вазыйфасына туры киләчәк;

биләгән вазыйфасына туры килми;

биләгән вазыйфасына туры килә һәм зуррак вазыйфага күтәрү өчен резервка кертергә киңәш ителә.

3.15. Аттестация нәтиҗәләре бер атна эчендә Театр җитәкчесенә хәбәр ителә.

3.16. Аттестация белән бәйле хезмәт бәхәсләрен карау хезмәт бәхәсләрен карау тәртибе турындагы гамәлдәге законнар нигезендә башкарыла.

Татарстан Республикасы дәүләт
театрларының профессиональ иҗат
хезмәткәрләрен аттестацияләү
турында типик нигезләмәгә кушымта

## АТТЕСТАЦИЯ БИТЕ

1. Фамилия, исем, әтисе исеме ________________________________________
2. Туган елы ________________________________________________
3. Белеме һәм квалификациясен күтәрү турында белешмә _______________

________________________________________________________________

(нәрсәне һәм кайчан тәмамлаган, белеме буенча белгечлеге һәм квалификациясе,

________________________________________________________________

гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)
4. Аттестация чорында биләгән вазыйфасы һәм әлеге вазыйфага билгеләнү датасы (сайлану, раслану) __________________________
5. Гомуми эш стажы, шул исәптән белгечлек буенча эш стажы _________

________________________________________________________________

6. Аттестацияләнүчегә сораулар һәм аның җаваплары ______________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

7. Аттестация комиссиясе әгъзаларының тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

8. Аттестацияләнүче хезмәткәрнең тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре _________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

9. Алдагы аттестациядәге рекомендацияләрнең үтәлеше _________________
10. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча хезмәткәрнең эшчәнлеген бәяләү:
биләгән вазыйфасына туры килә;
хезмәт эшчәнлеге буенча аттестация комиссиясе рекомендацияләрен үтәсә, бер елдан кабат аттестация үтү шарты белән биләгән вазыйфасына туры килә;
биләгән вазыйфасына туры килми;
биләгән вазыйфасына туры килә һәм зуррак вазыйфага күтәрү өчен резервка кертергә киңәш ителә.
Тавыш саны риза ____________, каршы ______________.

11. Аттестация комиссиясенең рекомендацияләре (бирелү сәбәпләрен күрсәтеп)

___________________________________________________

12. Искәрмәләр

Аттестация комиссиясе рәисе ______________________________________________

___________________________________________________________________________

Аттестация комиссиясе секретаре ___________________________________________

___________________________________________________________________________

Аттестация комиссиясе әгъзалары___________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Аттестация датасы ________________________________________________________

Аттестация бите белән таныштым ___________________________________________

(имза,

___________________________________________________________________________

имзаны ачыклап бирү, аттестацияләнүченең имза кую датасы)

___________________________________________________________________________